ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОДРОЖЖАНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮПРӘЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2021 ел 18 ноябрь Иске Чүпрәле № 5

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының 15.10.2019 ел, № 59/3 карары (15.11.2019 ел, № 60/6 редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе» нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлегенең Иске Чүпрәле торак пунктында гражданнар җыенын 2021 елның 7 декабренә 9.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Чүпрэле авылы,Дзержинский урамы, 36А йорт «Алтын» Спорт залы; адресы буенча беренче этап гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлегенең Иске Чүпрәле торак пунктында гражданнар җыенын 2021 елның 7 декабренә 10.30 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Чүпрэле авылы,Дементьев урамы, 4 йорт «Чемпион» Спорт залы; адресы буенча икенче этап гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлегенең Иске Чүпрәле торак пунктында гражданнар җыенын 2021 елның 7 декабренә 15.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Чүпрэле авылы,Үзәк урамы, 9 йорт Район мәдәният йорты; адресы буенча өченче

этап гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибен территориаль билге буенча билгеләргә.

5. Халыктан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабына кертергә киләсе урамнар: Сабантуй мәйданы, Яр буе урамe, Ленин ур., 1 - 25-нче йорт и 27 йорт, А. Абязов ур., Ямашев пр., Ямашев ур., Октябрьнең 50 еллыгы ур., Тукай ур.,пр.Дзержинский, Дзержинский ур., Юбилей ур., Завод ур., Березовая ур., Нафиев ур.

6. Халыктан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабына кертергә киләсе урамнар: Ш. Мөдәрис ур., Көньяк ур. Семенов ур., бертуган Рәкиповлар ур., Дементьев ур., Зеленая ур., З. Нури ур. Яшьлек ур., Тынычлык ур., Татарстан ур., Дуслык ур., Дачная ур., Луговая ур.

7. Халыктан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабына кертергә киләсе урамнар: Пионерская ур., М. Җәлил ур.,1,2,3,4-Ленин тыкрыгы, Күпер ур., Мәктәп ур. Ленин ур., 26 йорт һәм 28-122 нче номерлы йортлар, 2-нче Бишьеллык ур., Даруханә ур.,Культура ур. Төзүчеләр ур., Базар ур., Кооператив ур., Газ ур., Газ тыкрыгы, Зариф Алимов ур., Техническая ур., Совет ур.,Индустриаль ур., Яңа ур., Садовая ур., Низаметдинов ур., Үзәк ур.

8. Гражданнар җыенында түбәндәге мәсьәләне расларга:

"2022 елда Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:

- Иске Чүпрәле авылында урамнарны яктыртуне төзәтүгә;
- Тынычлык, З. Нури, Татарстан, Ш. Мөдәрис, Яшьлек, Каенлык урамнарына, Иске Чүпрәленең Газ тыкрыгына вак таш җәю;
- Иске Чүпрәледә зиратларны тоту;
- Иске Чүпрәле авылында иске агачларны кисү;
- Иске Чүпрәле авылы,Техник,Зеленая,Дементьев,З.Алимов,Тукай,Октябрьнең 50 еллыгы,Ш.Мөдәрис урамнарына ясалма юл тигезсезлеге урнаштыру.

«ӘЙЕ» «ЮК»

9. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

Иске Чүпрәле авыл җирлеге Башлыгы Урынбасары: Р.Д.Низамов